СОВЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**Яңасала авыл җирлеге Советы**
**карары**

**24 июль 2023 ел** **№78**

**Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 13.06.2019 ел, № 27 карары ( 13.09.2021 ел №30 үзгәрешләр белән) белән расланган "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Яңасала авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

2021 елның 30 апрелендәге 119-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге башлыгының Яңасала авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 июнендәге 27 номерлы карары (13.09.2021 ел, №30, үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Яңасала авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең төзелеш һәм җирдән файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 июнендәге 27 номерлы карары (13.09.2021 ел № 30, үзгәрешләр белән) белән расланган "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Яңасала авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 10 ст. 8 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Шәһәр төзелеше регламентында тиешле территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына карата:

җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән файдалану төрләре;

җир кишәрлекләренең чик (минималь һәм (яки) максималь) үлчәмнәре һәм рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрлары;

капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелешенең тышкы күренешенә таләпләр;

Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын куллануны чикләүләр;

шәһәр төзелеше регламенты билгеләнгән территориаль зона чикләрендә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру күздә

тотылган очракта, территорияне коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин итүнең рөхсәт ителгән минималь дәрәҗәсенең исәп күрсәткечләре һәм күрсәтелгән объектларның халык өчен территориаль мөмкин булган рөхсәт ителгән максималь дәрәҗәсенең исәп күрсәткечләре.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru), Арча муниципаль районының рәсми сайтында "Җирлекләр" бүлегендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңасала авыл
җирлеге башлыгы — А.И.Сафин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЯНГА-САЛСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
СОВЕТ ЯНГА-САЛСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609003024